КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 23 август г.Казань № 1001

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы коллегиясе составын һәм әгъзалары санын раслау турында» 2019 ел, 24 декабрь, 1189 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы коллегиясе составына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы коллегиясе составын һәм әгъзалары санын раслау турында» 2019 ел, 24 декабрь, 1189 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 18 август, 702 нче; 2021 ел, 18 август, 741 нче; 2022 ел, 14 гыйнвар, 13 нче; 2022 ел, 3 октябрь, 1064 нче; 2023 ел, 19 гыйнвар, 22 нче; 2023 ел, 16 май, 597 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы коллегиясе составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

коллегия составыннан Б.Н.Разиновны, Д.Р.Самигуллинны чыгарырга;

коллегия составына түбәндәгеләрне кертергә:

«Татарстан Республикасының Цифрлы трансформация үзәге» дәүләт казна учреждениесе директоры Алексей Евгеньевич Едельсковны;

Элемтә, мәгълүмат технологияләре һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсе җитәкчесе Юрий Сергеевич Никитинны (килешү буенча).

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин